**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЧҮРИ-БУРАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАРЫ

2018 ел, 10 сентябрь №89

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы "Чүри-Бураш авыл җирлеге" муниципаль берлегенең җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Чүри-Бураш авыл җирлеге Советы карар итте **:**

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Чүри-Бураш авыл җирлеге Советының 2014 елның 7 августыннан 62 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы «Чүри-Бураш авыл җирлеге» муниципаль берлегенең җирдән куллану һәм төзелешләр кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

10 статьяның унынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

төзүче - үзенең җир кишәрлегендә яки җир кишәрлегенә хокукы булган (бу хокук иясенә дәүләт (муниципаль) милкендәге капиталь төзелеш объектларына бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашырганда дәүләт хакимияте органнары (дәүләт органнары), "Росатом" атом энергиясе буенча дәүләт корпорациясе, "Роскосмос" космик эшчәнлек буенча дәүләт корпорациясе, бюджеттан тыш дәүләт фондлары белән идарә итү органнары яки җирле үзидарә органнары Россия Федерациясенең бюднет законнары билгеләгән очракта килешү нигезендә үз дәүләт (муниципаль) заказчының вәкаләтләрен бирелгән булса) капиталь төзелеш объектларын төзүне, реконструкцияләүне, капиталь ремонтлауны, сүтүне, шулай ук инженерлык эзләнүләрен үтәүне, аларны төзүне, реконструкцияләүне, капиталь ремонтлауны өчен проект документларын әзерләүне тәэмин итүче физик яки юридик зат. Төзүче шәһәр төзелеше законнарында каралган үз функцияләрен техник заказчыга тапшырырга хокуклы.”;

26 статьяның 1 пунктындагы икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Шәхси торак төзелеше объектын, бакча йортын төзегәндә, реконструкцияләгәндә проект документациясен әзерләү таләп ителми. Төзүче үз инициативасы буенча индивидуаль торак төзелеше объектына, бакча йортына карата проект документларын әзерләүне тәэмин итәргә хокуклы.”;

26 статьяның 8 пунктындагы 7 пунктчасында «яки демонтаж» сүзләрен һәм «яки "демонтаж" сүзләрен төшереп калдырырга;

26 статьяның 8 пунктындагы 10 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары, Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары, муниципаль берәмлекләр тарафыннан барлыкка китерелгән юридик затларның, Россия Федерациясенең, Россия Федерациясе субъектларының, муниципаль берәмлекләрнең өлеше устав капиталында 50 проценттан артык тәшкил иткән юридик затның акчаларын җәлеп итеп финанслана торган капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләүгә, капиталь ремонтлауга, сүтүгә сметалар, мәдәни мирас объектларын саклау буенча эшләр башкаруга смета;”

27 статьяның 5 пунктындагы 3 пунктчасының җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« - капиталь төзелеш объектын төзүне оештыру проекты;»;

27 статьяның 5 пунктындагы 3 пунктчасының сигезенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
« - капиталь төзелеш объектларын, аларның өлешләрен сүтү эшләрен оештыру проекты;».

2.Әлеге карарны Устав белән билгеләнгән тәртип нигезендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм махсус мәгълүмати стендларда бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны җирлк башлыгына йөкләргә.

**Чүри-Бураш авыл**
**җирлеге башлыгы** **И.Р.Мифтахов**